| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОТЯБЕРДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ТЭРБИТ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26 июнь, 2023 ел Иске Тэрбит ав. № 5

Иске Тэрбит авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 18 мартындагы 6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тэрбит авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тэрбит авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Иске Тэрбит авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 18 мартындагы 6 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Иске Тэрбит авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 статьяның 2 өлеше 2.3. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Россия Федерациясе законнары белән Россия Федерациясе Конституция суды компетенциясенә кертелгән мөрәҗәгатьләр.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кайбыч муниципаль районы Иске Тэрбит авыл җирлегенең https:// styaberdin-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырырга һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Иске Тэрбит авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчес В.Г.Тимофеев